КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1356

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасы турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасы турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 май, 385 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «системасы турында» сүзләрен «системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыру турында» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2021 – 2022 елларда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыру турындагы нигезләмәне;

2021 – 2022 елларда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыруга юнәлдерелгән чараларны финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләрен.»;

әлеге карар белән расланган 2021 елда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасы турындагы нигезләмәдә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021 – 2022 елларда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыру турында нигезләмә»;

1.1 пунктта «2021 елда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасы турында» сүзләрен «2021 – 2022 елларда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыру турында» сүзләренә алмаштырырга;

6.6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«медицина оешмасыннан белешмәләр кергән көндә әлеге белешмәләрне халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге белгечләренең граждан өендә булуын оештыру, аның тормыш шартларын тикшерү, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган тәртиптә типлаштыру, социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат бирү өчен халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенә тапшыра;»;

6.10 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«озак вакыт карау буенча хезмәт күрсәтелүче гражданның сәламәтлеге һәм эшчәнлеге торышында үзгәреш ачыкланган көннән өч эш көне эчендә озак вакыт карау буенча гражданга социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе тарафыннан аңа карата планнан тыш типлаштыру гамәлгә ашырыла һәм аның нәтиҗәләре социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын актуальләштерү өчен территориаль социаль яклау органнарына җибәрелә.»;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтаның нумерация башисемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021 – 2022 елларда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыру турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта»;

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтаның нумерация башисемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021 – 2022 елларда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыру турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта»;

әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтаның нумерация башисемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021 – 2022 елларда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыру турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымта»;

әлеге карар белән расланган 2021 елда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруны финанслар

белән тәэмин итү кагыйдәләрендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021 – 2022 елларда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыруга юнәлдерелгән чараларны финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләре»;

1 пунктта «булдыруга юнәлдерелгән» сүзләрен «булдыру буенча пилот проектын» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта татар текстында «булдыру» сүзеннән соң «буенча пилот проекты» сүзләрен өстәргә;

6 пунктның өченче абзацында «хезмәт өчен түләү һәм исәпләүләр» сүзләрен «комплектлап бетерү һәм өстәп исәпләнгән сумма белән хезмәт өчен түләү» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин